**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 5-40 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасы регламентына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Казан шәһәре Думасы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен җайга салу максатыннан, 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2005 елның 10 ноябрендәге 4-2 номерлы «Казан шәһәре Думасы регламенты турында»гы карары кушымтасына (Казан шәһәре Думасының 2006 елның 17 февралендәге 16-6 номерлы, 2006 елның 29 июнендәге 7-10 номерлы, 2006 елның 18 октябрендәге 29-12 номерлы, 33-12 номерлы, 2009 елның 29 апрелендәге 21-40 номерлы, 22-40 номерлы, 2009 елның 7 октябрендәге 16-43 номерлы, 2010 елның 8 октябрендәге 3-54 номерлы, 2010 елның 27 октябрендәге 18-1 номерлы, 2011 елның 21 декабрендәге 6-10 номерлы, 2012 елның 7 июнендәге 5-14 номерлы, 2013 елның 11 ноябрендәге 16-26 номерлы, 2014 елның 29 октябрендәге 10-37 номерлы, 2015 елның 4 мартындагы 32-41 номерлы, 2015 елның 21 сентябрендәге 15-1 номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 10-2 номерлы, 2016 елның 23 маендагы 16-7 номерлы, 2017 елның 21 июнендәге 9-17 номерлы, 2017 елның 17 августындагы 13-19 номерлы, 2019 елның 26 февралендәге 19-32 номерлы, 2019 елның 18 декабрендәге 14-37 номерлы, 2020 елның 15 маендагы 2-39 номерлы, 2023 елның 14 апрелендәге 19-22 номерлы, 2024 елның 22 ноябрендәге 22-34 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацында «Муниципаль берәмлек башлыгы» сүзләрен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (алга таба – муниципаль берәмлек башлыгы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4 статьяның 6 өлешендәге икенче абзацында «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (алга таба – муниципаль берәмлек башлыгы)» сүзләрен «Муниципаль берәмлек башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 6 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«6 статья. Шәһәр Думасы сессияләре секретариаты.

1. Шәһәр Думасының сайланган составының беренче сессиясендә чакырылышның эшләү чорына ачык тавыш бирү юлы белән депутатлар арасыннан Секретариатның җитәкчесе һәм ике әгъзасы составындагы Секретариат сайлана.

Секретариат җитәкчесе булмаган очракта, аның вазифаларын Секретариат әгъзаларының берсе башкара.

Секретариатның барлык әгъзалары бер үк вакытта булмаганда, агымдагы сессия чорына шәһәр Думасы депутатлары тарафыннан Секретариат сайлана.

2. Шәһәр Думасы сессияләре секретариаты:

- сессияне үткәрү тәртибенә кагылышлы өлешендә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлешен тәэмин итә;

- чыгышлар өчен язылуны алып бара, депутат таләпләрен һәм мөрәҗәгатьләрен, депутатлардан, шулай ук гражданнардан килә торган сорауларны, белешмәләрне, гаризаларны, тәкъдимнәрне һәм башка материалларны терки, аларны тиешле урынга җибәрә;

- рәислек итүчегә һәм депутатларга килеп ирешкән материаллар турында мәгълүмат бирә;

- тавыш бирүнең барышын һәм дөреслеген тикшереп тора, карарлар кабул иткәндә тавыш бирү нәтиҗәләрен саный;

-карар проекты текстына кертелүче төзәтмәләрне игълан итә (төзәтмәләр булганда);

- Шәһәр Думасы сессиясе беркетмәсен алып бара»;

1.4. 11 статьяда:

1.4.1. 1 өлештә «Шәһәр Думасы аппараты» сүзләрен «Оештыру идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

1.4.2. 3 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Сораштыру юлы белән тавыш бирү уздырылган көнне Президиум яисә даими комиссия әгъзасы электрон элемтә чаралары ярдәмендә үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган сораштыру кәгазен, аның оригиналының

график образы рәвешендә оештыру идарәсенә тапшыра. Сораштыру кәгазенең төп нөсхәсе Президиумның яисә даими комиссиянең чираттагы утырышын уздыру көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Депутатларның тавышларын санау һәм сораштырып тавыш бирү йомгакларын ясау Оештыру идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

1.5. 13 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Шәһәр Думасына карар проектларын кертү хокукына муниципаль берәмлек башлыгы, депутатлар, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе, Казан шәһәренең контроль-хисап палатасы рәисе, Казан шәһәре прокуроры, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары һәм гражданнарның инициатив төркемнәре ия»;

1.6. 18 статьяның тугызынчы абзацында «редакция комиссиясе» сүзләрен «секретариат тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 19 статьяда:

1.7.1. 3 өлештә «сорау бирелә» сүзләреннән соң «секретариатка» сүзләрен өстәргә;

1.7.2. 6 өлештә «редакция комиссиясе» сүзләрен «секретариатның» сүзенә алмаштырырга;

1.8. 22 статьяның 1 өлешендә «залда» сүзеннән соң «(урыннан)» сүзләрен өстәргә;

1.9. 25 статьяның 2 өлешендә «хисап комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «секретариат тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 26 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Яшерен тавыш бирүне үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен билгеләү өчен Шәһәр Думасы депутатлар арасыннан өч кеше составындагы махсус төзелгән хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясенә кандидатуралары сайланучы органнар составына яисә вазифаи зат вазифасына күрсәтелгән депутатлар керә алмый. Хисап комиссиясе үз составыннан комиссия рәисен һәм секретарен сайлый»;

1.11. 27 статьяда:

1.11.1. 5 өлештә «сессия эшенең башында сайланган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11.2. 7 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«7. Исемләп тавыш бирү бланкларын кабул итү секретариат тарафыннан Шәһәр Думасы билгеләгән вакытка кадәр гамәлгә ашырыла»;

1.11.3. 8 өлештә «тавыш бирү игълан ителә» сүзләреннән соң «секретариат тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

1.12. 33 статьяда:

1.12.1 1 өлешнең беренче абзацында «Шәһәр Думасы аппаратында» сүзләрен «Оештыру идарәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.12.2. 3 өлешнең икенче абзацында «Шәһәр Думасы аппаратында саклана торган» сүзләрен «Оештыру идарәсендә саклана торган» сүзләренә алмаштырырга;

1.13. 34 статьяда:

1.13.1. 1 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Муниципаль берәмлек башлыгы шәһәр Думасы депутатларының билгеләнгән саныннан яшерен тавыш бирү юлы белән Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан шәһәр Думасы тарафыннан сайлана»;

1.13.2. 1 өлештән соң түбәндәге эчтәлекле 2 һәм 3 өлешләр өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлек башлыгы вазифасына керешү тантаналы шартларда Шәһәр Думасы утырышында уза, анда сайланган муниципаль берәмлек башлыгына Казан Мэры вазифаи билгесе тапшырыла.

3. Шәһәр Думасы депутаты булып торучы муниципаль берәмлекнең сайланган башлыгы Шәһәр Думасы рәисе вәкаләтләрен башкара»;

1.13.3. 2 өлешне 4 өлеш дип санап, аны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Муниципаль берәмлек башлыгы сайланган көненнән муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен, ә әлеге статьяның 3 өлешендә каралган очракта – Шәһәр Думасы рәисе вәкаләтләрен үтәүгә керешә»;

1.13.4. 3 – 4 өлешләрне 5 – 6 өлешләр дип санарга;

1.14. 41 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«41 статья. Депутат фракцияләре һәм аларның эшчәнлек тәртибе.

1. Сәяси партияләр (аларның региональ бүлекләре яисә башка структур бүлекчәләре) тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлекләре составында сайланган депутатлар, сәяси партия бетерелүгә яисә үзгәртеп оештырылуга бәйле рәвештә аның эшчәнлеге туктатылудан тыш, депутат фракцияләренә (алга таба – фракция) керәләр.

2. Фракциянең тулы исеме – кандидатлар исемлеге составында тиешле депутатлар сайланган сәяси партия уставында күрсәтелгән исем. Фракция турындагы нигезләмәдә билгеләнгәнчә, фракциянең тулы исеменә туры килә торган кыска исеме булырга хокуклы.

3. Фракцияләр хәбәр итеп теркәлергә тиеш. Шәһәр Думасына теркәлү өчен түбәндәге документлар тапшырыла:

- аның рәсми атамасын, фракция җитәкчесен һәм шәхси составын сайлау турындагы мәгълүматларны үз эченә алган фракция төзү турындагы карар;

- фракция җитәкчесенең фракцияне төзү турында язма хәбәрнамәсе;

- фракциянең оештыру җыелышында кандидатларның тиешле исемлеге составында сайланган депутатларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән раслана торган фракция турындагы нигезләмә.

4. Яңа теркәлгән фракция турында белешмәләр, шулай ук күрсәтелгән фракциягә керүче депутатлар турында белешмәләр, фракция теркәлгәннән соң иң якындагы шәһәр Думасы сессиясендә игълан ителә.

Әлеге статьяның 4 өлешендәге 2 абзацында күрсәтелгән мәгълүмат үзгәргән очракта, фракцияләр Шәһәр Думасына хәбәр итәләр, шуннан соң әлеге мәгълүмат шәһәр Думасының якындагы сессиясендә игълан ителә.

5. Фракциянең эчке эшчәнлеге аның тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, фракция турындагы нигезләмә нигезендә оештырыла.

6. Бермандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керүче Депутат аннан хәбәр итү тәртибендә чыгарга хокуклы.

Депутатның фракциядә әгъзалыгын туктату турындагы мәгълүмат, депутатның фракциядә әгъзалыгын туктатканнан соң, якындагы шәһәр Думасы сессиясендә игълан ителә.

7. Фракция бетерелүгә яисә үзгәртеп оештырылуга яки фракциягә кергән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатларның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә фракция эшчәнлегенең туктатылуы турындагы мәгълүмат, фракциядә мондый исемлек составында сайланган депутатларның булмавына китереп чыгара һәм фракция эшчәнлеге туктатылганнан соң иң якындагы шәһәр Думасы сессиясендә игълан ителә»;

1.15. 47 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Шәһәр Думасы эшли башлаган көннән туктатыла.

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешендә һәм 30 статьясындагы 1, 2 өлешләрендә билгеләнгән очракларда, депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 30 статьясындагы 1 өлешенең 2, 6, 7, 9 пунктларында билгеләнгән очракларда, депутат вәкаләтләрен туктату вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату турындагы гаризада күрсәтелгән көннән вакытыннан алда дип санала.

Депутатның әлеге өлешнең өченче абзацында каралган нигезләр буенча вәкаләтләрен туктату, депутат вәкаләтләрен туктату көнен күрсәтеп, Казан шәһәре Уставының 32 статьясы нигезендә шәһәр Думасы карары белән рәсмиләштерелә»;

1.16. 52 статьяның 2 өлешендә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы “Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында”гы федераль законы, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы “Аерым категориягә караган затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында”гы федераль законы белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның 1.13.2. пунктчасының өченче абзацы Казан шәһәре Думасы рәисе вәкаләтләрен башкаручы Казан шәһәре Мэрына карата 2027 елның 1 гыйнварына кадәр сайланган Казан шәһәре Думасы вәкаләтләре чоры тәмамланганчы гамәлдә була.

4. Казан шәһәре Мэрын сайлауның әлеге карарның 1.13 пункты белән билгеләнгән тәртибе әлеге карар гамәлгә кергәннән соң сайланган Казан шәһәре Мэрына карата кулланыла.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**